**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Тимбай  авыл җирлегенең Тимбай  авылында гражданнар җыены карары**

22 март 2024 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Тимбай  авыл җирлегенең Тимбай  авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы  Тимбай   авыл җирлегенең Тимбай авылы гражданнары җыенының 2023 елның 15 ноябрендәге  1нче номерлы карарының 2 пунктына үзгәрешләр кертергә һәм аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Җыелган акчаны түбәндәге  җирле  мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту;

- Тимбай авылында торак пункт территориясен төзекләндерү (ял паркын төзекләндерү, кышкы чорда юлларны тоту ,җәйге вакытта территорияне чабу, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү).»

2. Җыен нәтиҗәләрен  Тимбай  авыл җирлегенең  Тимбай  авылында  махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Тимбай   авыл җирлеге башлыгы _________   И.Г. Айзатуллин

Халык җыены секретаре _________  Г.А. Хәкимова